КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 28 февраль

г.Казань

№ 171

Татарстан Республикасында «Цифрлы трансформация» Россия Федерациясе үсешенең милли максатларын гамәлгә ашыру турында

Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясе үсешенең милли максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы Указы, «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Президентының «2022 елны Татарстан Республикасында цифрлаштыру елы дип игълан итү турында» 2021 елның 8 октябрендәге ПУ-800 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 - 2024 елларга Татарстан Республикасын цифрлы трансформацияләү концепциясен раслау турында» 2021 ел, 29 гыйнвар, 35 нче һәм «Татарстан Республикасы икътисад, социаль өлкә һәм дәүләт идарәсе тармакларын цифрлы трансформацияләү өлкәсендә стратегияне раслау турында» 2021 ел, 18 август, 748 нче карарлары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елда Татарстан Республикасында Цифрлаштыру елын үткәрү буенча чараларның беркетелгән планын (алга таба - План) расларга.
2. Планны тормышка ашыру өчен җаваплы Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына аның чараларын үтәүне тәэмин итәргә.
3. Федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары булмаган Татарстан Республикасы дәүләт органнары, оештыру-хокукый рәвешенә бәйсез рәвештә оешмалар җитәкчеләренә Планны гамәлгә ашыруда ярдәм күрсәтергә тәкъдим итәргә.

4. План чараларын финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджетында 2022 елга Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына каралган ассигнованиеләр чикләрендә, шулай ук аерым кабул ителә торган карарлар буенча гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

5. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына «Клиентларга үзәкләштерелгән цифрлы хезмәтләр күрсәтүнең бүленгән архитектурасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына тоташканда мәгълүматны криптографик яклауның сертификацияләнгән чараларыннан файдалануны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

6. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына һәм дәүләтнең катнашу өлешләре булган оешмаларга, шулай ук директорлар советына дәүләт вәкилләре кергән оешмаларга, законнарны үзгәртүне һәм чит ил производствосын программа белән тәэмин итүне тыюны исәпкә алып, программа белән тәэмин итүне сатып алуны гамәлгә ашырырга тәкъдим итәргә.

7. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына «Таттелеком» гавами акционерлык җәмгыяте белән үзара хезмәттәшлектә (килешү буенча) «Имин шәһәр» аппарат-программа комплексының хокук саклау сегментын гамәлгә ашыру кысаларында видеокүзәтү муниципаль системаларын үстерүне дәвам итәргә;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына һәм директорлар советына дәүләт вәкилләре кергән оешмаларга, законнарны үзгәртүне һәм чит дәүләтләрдән килә торган сәнәгать товарларын дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен сатып алулар, шулай ук чит дәүләтләрдән килүче сәнәгать товарларын сатуны тыюны исәпкә алып, җиһазлар һәм исәпләү техникасын сатып алуны гамәлгә ашырырга;

«Россия телевизион һәм радиотапшырулар челтәре» федераль дәүләт унитар предприятиесенең «Татарстан Республикасы Радиотелевизион тапшыру үзәге» филиалына Татарстан Республикасында цифрлы эфир телетапшырулары челтәренең өзлексез эшләвен тәэмин итәргә.

8. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына 2022 елда Татарстан Республикасында цифрлаштыру елын үткәрү чараларын мәгълүмати озата баруны тәэмин итәргә.

9. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин